**ГЛАВА АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 27 от 18.03.2026

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләр чикләрен билгеләү турында»карары проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән якын территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү һәм алкоголь продукциясен ваклап сату кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 24 августындагы 175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать фикер алышуларын оештыру тәртибе һәм (иҗтимагый фикер алышуларны) турында нигезләмәгә таянып

**карар итәм :**

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләр чикләрен билгеләү турында»карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы – оештыру комитеты составын расларга:

1)Зәмдиханов Рөстәм Зефяр улы - Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары;

2)Әмирова Эльвира Юрьевна-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы;
3) Шакирова Эльмира Фирдүс кызы-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручыга-оештыру комитетына җәмәгать фикер алышуларын законнар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4.Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү 2026 елның 11 апреленнән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары Хантимеров Ленар Тәлгать улына йөкләргә.

**Башлык** **А.Г. Җиһаншин**